Оригинальность -90%

**Семинар-практикум для родителей в младшей группе**

**«Бала — бәгырь җимеше»**

*Хамидуллина Людмила Винидимовна,*
воспитатель МАДОУ «Детский сад комбинированного вида № 23
«Светлячок»г. Набережные Челны РТ

**Максат:**Әти – әниләрне балалар белән эшчәнлектә кулланыла торган төрле алымнарга өйрәтү, алар белән эзлекле бәйләнештә булуны тәэмин итү.

**Бурычлар:**

1. Әти-әниләрне бер-берсе белән таныштыру.

2.Әти-әниләргә үз балалаларын аңларга, аларның эмоциональ иминлеге турында кайгыртырга ярдәм итү.

**Җиһазлар һәм күрсәтмәлелек:** Тәкъдим ителгән хәлләрне сәхнәләштерү өчен кирәк-яраклар, җырлар яздырылган диск.

**Техник чаралар:** Магнитофон, интерактив такта, ноутбук,презентация.

**Залның бизәлеше:** өстәл, урындыклар, бала һәм ата-ана турында мәкальләр һәм әйтемнәр язылган плакатлар.

**Ата-аналар белән алдан әзерлек эше:** Җырлар, уеннар, мәкальләр өйрәнү,анкета сорауларына җавап бирү.

**Семинар барышы.**

Балалар без теләгәнчә булсалар,
җирдә барытик генийлар гына яшәр иде .
*Иоганн Вольфганг Гете*

(Әти-әниләр һәм тәрбияче түгәрәк ясап утыралар)

**Тәрбияче:** Исәнмесез, хөрмәтле әти – әниләр, кунаклар! Бүген без сезнең белән беренче тапкыр бер гаилә булып җыелдык һәм бик барыбызны да борчыган «Бала — бәгырь җимеше»дигән темага сөйләшү алып барырбыз. Иң элек якыннанрак танышып үтик. (Түгәрәктә утыручы һәр әти-әни үзенең исемен, баласының исемен һәм үзләренең генә ягымлы итеп ничек эндәшүләрен әйтеп, кулындагы йомшак уенчыгын күршесенә бирә).

**Тәрбияче чыгышы:**

Яңа килгән баланың балалар бакчасына килгәч тә, өйдәгедән бөтенләй аерылып торган яңа шартлар, яңа мохитка килеп эләгүен күп кенә ата-аналар аңлап та җиткерми.

Сабыйга яңа учреждение, яңа кешеләр, таныш түгел иптәшләр, өлкәннәр, режим моментларына ияләшеп китүе бик тә авыр.

Ата-аналар да бала өченборчылалар, балаларбакчасыталәпләренә ияләшәләр. Шулуквакыттатәрбиячегәдә бала һәмата-аналарыбеләнякынмөнәсәбәтләрурнаштыруыҗиңелтүгел.

Бала, балалар бакчасына карата уңышлы адаптация чоры үтсен өчен, ата-аналарның бакчага карата уңай мөнәсәббәттә булулары, балада да шундый фикер тәрбияләүләре шарт.

Баланың адаптация процессына аның психик һәм физик үсеше, сәламәтлеге, чыныгуы, үз-үзенә хезмәт күрсәтә белүе, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән коммуникатив аралашуы, сабыйның шәхси үзенчәлекләре, ата-аналарның борчылу дәрәҗәләре дә тәэсир итә. Әгәр алда әйтеп үткәннәр балада булмаса яки түбән дәрәҗәдә булса микросоциаль шартларда адаптация

чоры авыррак үтә. Баланың сәламәтлегенә зыян килә, чөнки эмоциональ стресс реакциясе үсеш ала.

Эмоцияләр дип кешенең уй-кичерешләрен, тойгы-хисләрен атыйлар. Бу тойгылар кешедә яхшылык-яманлык, канәгатьлек һәм канәгать булмау, рәхәт-михнәт кебек хисләрнең төрле-төрле төсмерләре аша чагыла. Галимнәр раслаганча сигез атналык сабый балада да иң гадиләрдән саналган канәгать булу һәм канәгатьсезлек хисе бар. Бала үскән саен аның кичергән хис-кичерешләре дә катлаулана бара. Биш яшендә инде ул шатлык, ярату, сагыну, көнчелек, горурлык һәм оят хисе белән таныш.

Эмоцияләр ярдәмендә бала үзенең кәефен, теләк-ихтыяҗын өлкәннәргә җиткерә. Эмоцияләрнең катлаулыгы бала үзе үскән саен арта һәм бу процесс 10 яшькә кадәр дәвам итә.

Баланың эмоциональ тирәлеге үсешендә гаилә,балалар бакчасы, мәктәп, баланы әйләндереп алган мөхитнең ниндилеге зур роль уйный.

Эмоцияләр кеше эшчәнлегенең барлык төрләренә дә йогынты ясый.

Эмоцияләрнең бертөрлеләре турыдан-туры баланың танып белү, уйлау-фикерләү, иҗади эшчәнлегенә тәэсир итә, икенче төрле әйткәндә, белемне үзләштерүнең нәтиҗәлелеген билгели. Бу төр хисләрне интеллектуаль хисләр дип атыйлар. Аларга кызыксынучанлык, күп белергә теләү, яңалыкка омтылыш, гаҗәпләнү, икеләнү, ышаныч кебек эмоцияләр керә.

Баланың шәхес булып формалашуында интеллектуаль эмоцияләрдән тыш, әхлакый хисләр дә зур әһәмияткә ия. Кешенең әхлакый тормышындагы эмоциональ якны горурлык, намус, вөҗдан, нәфрәт, оялу, һавалану, үз-үзеңне артык ярату, дуслык, патриотизм кебек хисләр билгели.

Эмоциональбәйләнешнеңәһәмиятебикзур! Сабыйһәрдаимүзенеңкадерле, көтепалынганбулуын, яратуларынтоепторыргатиеш. Шулочрактагынааның күңелендә «тирә-юньдәгеләр, дөньябеләнгармониядәяшим», «мин аларгакирәк», «мин үземдәаларныяратам» дигәнышанычтуа.

Әгәр ул елаганда, нидер таләп иткәндә әнисе ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышса, бала «әнигә ышанырга ярамый» дигән нәтиҗә ясап кына калмаячак, «кешеләргә, бу дөньяга өмет багларга кирәкми икән» дигән карарга да киләчәк.

Бала көйсезләнгән вакытта, аңа үзенә сайлау мөмкинлеге тәкъдим итәргә кирәк. Мәсәлән: “ Син уенчыкларыңны хәзер җыясыңмы, әллә мультфильм карагачмы?”, “Башта тешләреңне чистартасыңмы, әллә пижамаңны киясеңме?”

Балалар бакчасына йөри башлагач, ияләнгәнче, баланың кәефе үзгәрүчән була.Бу очракта әти-әниләргә сабыр булу кирәк. Бик кулай ысул- уеннар.Уен вакытында бала бар нәрсәне үзе теләгәнчә эшлим дип уйлый.

Сезгә шундый очрак тәкъдим итәм.

1. Өйгә кайтып җитәбез дигән вакытта, бала көйсезләнә башлый, “барасым килми”, -ди. (Түгәрәктә утырган килеш, уң як күршеләре белән парлашып уйлыйлар һәм үзләренең җавапларын әйтәләр)
2. Әгәр дә тыңламасаң, сине әнә теге бабай алып китә,-ди әнисе. (Түгәрәктә утырган килеш, сул як күршеләре белән парлашып уйлыйлар һәм үзләренең җавапларын әйтәләр)

**Тәрбияче мисалы:** Әни: “Әйдә мин кара ат, ә син ак ат буласын. Кайсы ат тизрәк кайтып җитәр икән?” (Баланы куркытып, тыңларга өйрәтергә ярамый. Кечкенә балалар, әйткән сүзгә ышаналар, бигрәк тә әти-әни сүзенә.)

Ә хәзер хөрмәтле эти-әниләр, 2 түгәрәк ясап утырыгыз, төркемнәрдә эшләп алабыз. (Төркемнәргә фикерләшергә һәм сәхнәләштереп күрсәтергә тәкъдим ителә)

**1 төркем:**

Инде соң, балага йоклар вакыт җиткән. Әнисе ничек булса да баланы йокларга ятарга үгетли. Шул вакыт әтисе, иртәгә ял икәнен искә төшереп, тагын әзерәк уйнарга рөхсәт итә. Ә әнисе үз сүзендә тора.

**2 тәркем:**

Әнисе 3 яшьлек улын теш чистартырга өйрәтә. Әтисе бала янында үзенең 5 яшьтә генә өйрәнгәнлеген һәм баланы ирексезләргә кирәк түгел дигән фикерен әйтә.

**Тәрбияче фикере:** бала тәрбияләүдә эти белән әнинең бер фикердә булулары шарт.

**Тәрбияче:**Бала шәхесен үстерүгә юнәлтелгән тагын бер эмоциональ хисләр турында әйтеп китмичә булмый – бу эстетик хисләр тәрбияләү. Эстетик (гүзәллек турында) хисләр безнең тормышта искиткеч көчкә ия. Матурлыкны күрә белү, аңлый белү, тудыра белү безнең тормышны баерак, кызыклырак итә, рухи ләззәтләнү бирә. Без кешенең һәрьяклы үсешенә омтылабыз, шуңа күрә һәр балада эстетик хисләр тәрбияләргә тиешбез. Эстетик хисләргә соклану, шатлык, сагыш, матурлыкны күрә белү, ярату керә.Кеше тормышында бишек җырларының урыны дәрәҗәле.Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакыттабашкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга,уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп әйтергә омтыла.Бишек җырларында аналарның теләкләре, ышанычлары, баласын рухи һәмфизик яктан матур, булдыклы, игелекле, мәрхәмәтле гади итеп күрү өметләречагыла.

-Ә сез хөрмәтле әниләр нинди бишек җырлары беләсез?

(Санамыш ярдәмендә түгәрәктә утырган эти-әниләр арасыннан сайлана)

-Хәзер без сезнең белән балачакка кайтып килик, бергәләшеп түгәрәккә басыйк. Без “Шаян яңгыр” уенын уйнап алырбыз.

(Әти-әниләр түгәрәктә бер-бер артлы басалар, тәрбияче: шаян яңгыр ява башлады: ул муеннарга ява, иң өсләренә ява, аркага ява...ди. Катнашучылар түгәрәк буйлап баралар, күнегүләрне үтиләр. Ә аннары икенче якка борылалар)

**Тәрбияче чыгышы:**Әгәр дә без – өлкәннәр балаларга игътибарлы икән, аларны шәхес буларак кабул итеп яратабыз , алар белән борчылабыз, шатлыкларын үзебезнеке кебек кабул итеп сөенәбез икән, аларның кечкенә генә уңышларын күреп мактый беләбез икән, алар эмоциональ канәгатьлек кичерәләр, аларда уңай сыйфатлар арта, кешеләргә ягымлы мөнәсәбәт формалаша. Әйдәгез, балаларыбызга игътибарыбызны, назыбызны кызганмыйк, алар өчен иң матур, иң әйбәт, иң белемле идеал булыйк!

**Әдәбият исемлеге.**

1. “Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе” методик кулланма. Закирова К.В. Казан: Мәгариф, 1999-224б.
2. Развивающие игры с малышами до трёх лет. Популярное пособие для родителей и педагогов. Ярославль,”Академия развития”, 1997

**Исегездә тотыгыз!**



**Үзегезнең балагызга сөенегез!!!**

-Гаиләдә тыныч, дусларча атмосфера булдырырга тырышыгыз.

- Түземле булыгыз.

- Бала сезнең белән сөйләшкәндә аны игътибар белән тыңлагыз.

- Бала сезнең белән сөйләшкәндә аны игътибар белән тыңлагыз.

- «Комачаулама!», «Көйсезләнмә!», «Тизрәк!», «Синнән бернәрсә дә килеп чыкмас!», «Кушканны тыңла!», «Әйбәт бул!» кебек турыдан-туры әйтүләр урынына, «Акыллым минем!» «кояшым минем», «алтыным» дип эндәшүләр кулланыгыз.

- Бала белән бергә иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнегез: уйнагыз, әвәләгез, рәсем ясагыз, . . .

-Кызыксынучанлыгын үстерегез.

- Мактауга саранланмагыз.

-Баладан: “Син нәрсә эшлисең?” дип сорагыз.

-Җыелган ачуыгызны баладан алмагыз.